**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

11.12.2017 1483-п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының 2012 елның 23 апрелендәге 148-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының калдыклар барлыкка килү, аларны файдалану, йогышсызландыру һәм урнаштыру турында хисаплылык (статистика хисаплылыгыннан кала) турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Экология һәм Табигый ресурслар министрлыгының норматив хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының 2012 елның 23 апрелендәге 148-п номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының 2013 елның 07 маендагы 266-п номерлы, 2013 елның 24 сентябрендәге 539-п номерлы, 2015 елның 29 декабрендәге 1126-п номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының калдыклар барлыкка килү, аларны файдалану, йогышсызландыру һәм урнаштыру турында хисаплылык (статистика хисаплылыгыннан кала) турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлектә:

1.1 пунктының беренче абзацында "контроленә" сүзен "күзәтчелегенә" сүзе белән алмаштырырга;

1.1 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Әлеге Регламент гамәле радиоактив, биологик һәм медицина калдыклары белән эш итү мәсьәләләренә кагылмый";

1.2 пунктының өченче абзацында "карый торган" сүзләрен "караган" сүзенә алмаштырырга;

1.3 пунктының 1.3.2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1.3.2. Министрлыкның территориаль идарәләренең эш графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән кала, дүшәмбе-пәнҗешәмбе: 8.00 башлап 17.00 кадәр, җомга: 8.00 башлап 15.45 кадәр, төшке аш: 12.00 башлап 12.45 кадәр.

Гаризалар Министрлыкның территориаль органнарының эш сәгатьләрендә кабул ителә.

Керү шәхесне таныклый торган документ буенча.

Министрлыкның дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы булган территориаль идарәләре турында мәгълүмат 1 таблицада күрсәтелде.

1 таблица. Министрлыкның дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы булган территориаль идарәләре турында белешмәләр

| Территориаль орган | Адресы | Телефоны, электрон почта адресы | Җәмәгать транспортында килү | Хезмәт күрсәтә торган территорияләре |
|---|---|---|---|---|
| Үзәк территориаль идарәсе | 420049, Казан ш., Павлюхин ур., 75 | (843) 267-68-33 Petr.Korolev @tatar.ru | автобуслар: №№ 2, 4, 5, 25, 31, 37, 43, 47, 69, 69а, 74, 74а, 77; троллейбуслар: №№ 6, 8, 12 – "Павлюхин" тукталышына кадәр | Казан ш., Биектау муниципаль районы (алга таба – МР), Лаеш МР, Питрәч МР, Югары Ослан МР, Яшел Үзән МР, |
| Төньяк территориаль идарәсе | 422000, Арча ш., Интернационал ур., 41 | (84366) 3-21-61 sevtu@mail.ru | автобус | Арча ш., Арча МР, Әтнә МР, Балтач МР, Кукмара МР, Саба МР, Теләче МР, |
| Идел арьягы территориаль идарәсе | 422430, Буа ш., Р.Люксембург ур., 159/1 | (84374) 3-11-02 3-34-46 zvtu@bk.ru | №1 автобус белән "Люксембург" тукталышына кадәр | Буа ш., Буа МР, Апас МР, Чүпрәле МР, Кайбыч МР, Кама Тамагы МР, Тәтеш МР, |
| Идел-Чулман территориаль | 422980, Чистай ш., | (84342) 5-35-19 | № 1, 21 автобуслар | Чистай ш., Чистай МР, |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| идарәсе | Фрунзе ур., 97а | 5-03-68 Rafis.Ahmetzyanov@tatar.ru | белән "Фрунзе" тукталышына кадәр | Аксубай МР, Алексеевск МР, Әлки МР, Балык Бистәсе МР, Спас МР, Яңа Чишмә МР |
| Чулман аръягы территориаль идарәсе | 423552, Түбән Кама районы, Красный Ключ пос., Набережная ур., 7 | (88555) 45-66-56 43-90-70 zakamtu@mail.ru | № 2 трамвай белән "Красный Ключ" тукталышына кадәр | Түбән Кама ш., Түбән Кама МР, Зәй МР, Сарман МР, |
| Чулман буе территориаль идарәсе | 423838, Яр Чаллы ш., Җиңүгә 40 ел ур., 64 | (8-8552) 59-36-39 59-50-46 prirodart@mail.ru | №№ 1б, 3, 10а, 25, 35 автобуслар белән "Форт Диалог" тукталышына кадәр | Яр Чаллы ш., Тукай МР, Актаныш МР, Әгерҗе МР, Менделеевск МР, Минзәлә МР, Мамадыш МР, Алабуга МР |
| Ык буе территориаль идарәсе | 423330, Азнакай ш., Шоссейная ур., 6 | (8-85572) 2-39-86 (8-85592) 51-5-38 eco.azn@mail.ru | № 5 автобус белән "Шоссейная" тукталышына кадәр | Азнакай ш., Азнакай МР, Баулы МР, Мөслим МР, Ютазы МР |
| Көньяк-Көнчыгыш территориаль идарәсе | 423450, Әлмәт ш., Әминов ур., 9а | (8-8553) 33-03-25 33-03-27 uvgri@tatais.ru | № 5 автобус; № 1 троллейбус белән "Әминов" тукталышына кадәр | Әлмәт ш., Бөгелмә МР, Лениногорск МР, Нурлат МР, Чирмешән МР |

1.3 пунктының 1.3.5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1.3.5. Мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 1.3.2, 1.4, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) булган дәүләт хезмәте турында белешмәләрне үз эченә ала.

1.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1.4. Дәүләт хезмәте түбәндәгеләргә нигезләнеп күрсәтелә:

"Җитештерү һәм куллану калдыклары турында" 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – № 89-ФЗ Федераль закон), (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 1998, № 26, 3009 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

"Әйләнә-тирәлекне саклау турында" 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 7-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2002, № 2, 133 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

"Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон), (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

"Электрон имза турында" 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2011, № 15, 2036 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Федераль дәүләт экология күзәтчелегенә тиешле объектларны ачыклау криетрияләрен раслау турында" 2015 елның 28 августындагы 903 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 903 номерлы карары), (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 07.09.2015, № 36, 5043 ст.);

Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының "Калдыклар барлыкка килү, аларны файдалану һәм урнаштыру турында хисаплылык (статистика хисаплылыгыннан кала) тапшыру һәм аны тикшереп тору тәртибен раслау турында" 2010 елның 16 февралендәге 30 номерлы боерыгы (алга таба – РФ Табигать министрлыгының 30 номерлы боерыгы)("Российская газета", 23.04.2010, № 87);

2009 елның 15 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Экология кодексы (алга таба – ТР Экология кодексы) (Татарстан Республикасы Дәүләт Советы җыелма басмасы, 2009, № 1, 5 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы мәсьәләләре" 2005 елның 06 июлендәге 325 номерлы карары (алга таба – 325 номерлы ТР МК карары) ("Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы" журналы, 2005, № 28, 0654 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында" 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карары (алга таба – Тәртип) ("Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы" журналы, 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып).

2 бүлектә:

"Стандартка карата таләпләр эчтәлеге" графасының 2.4 пунктында түбәндәге эчтәлекле икенче абзац өстәргә:

"Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган";

"Стандартка карата таләпләр эчтәлеге" графасының 2.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Хисаплылыкны кабул итү өчен түбәндәгеләр тапшырыла:

1. Хисаплылык кабул итү турында гариза (2 нче кушымта);

2. Хисаплылык;

3. Хисап чоры буенча калдыкларны башка юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга тапшыру яки башка юридик затлардан һәм шәхси эшкуарлардан кабул итү турында шартнамәләрнең күчермәләре һәм күрсәтелгән шартнамәләр буенча калдыкларны кабул итү-тапшыру актлары күчермәләре;

4. Лом һәм кара һәм төсле металл калдыклары кабул итү турында кабул итү-тапшыру актларының күчермәләре.

Хисаплылык "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә табигатьтән файдаланучыга хисаплылык әзерләү өчен Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең рәсми сайтында рөхсәт ителгән "Табигатьтән файдаланучы модуле": http://rpn.gov.ru түләүсез чарасы ярдәмендә формалаштырыла.

Дәүләт хезмәте алу буенча гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар Министрлыкның тиешле территориаль идарәсенә кәгазьдә бер нөсхәдә тапшырыла (җибәрелә). Хисаплылык шулай ук XML форматындагы электрон документ рәвешендә дә тапшырыла.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

шәхсән (ышанычнамә нигезендә мөрәҗәгать итүче исеменнән гамәл кылучы зат тарафыннан);

кушып тапшырылганнарның исемлеге һәм кулга тапшыру тамгасы белән почта аша җибәреп.

Гариза һәм теркәлә торган документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең рәсми сайтында урнаштырылган: http://rpn.gov.ru/msp "Дәүләт контроле" программа-технология комплексы" федераль дәүләт мәгълүмат системасында табигатьтән файдаланучының шәхси кабинеты аша электрон документ рәвешендә дә тапшырыла (җибәрелә) ала (алга таба – "Дәүләт контроле" ПТК" ФДМС).

Мөрәҗәгать итүче гаризаны һәм сканер аша чыгарылган документларны "Дәүләт контроле" ПТК" ФДМС аша көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) электрон документ рәвешендә тапшырган очракта, күрсәтелгән документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче (аның вәкиле)

тарафыннан Министрлыкның тиешле территориаль идарәсенә кәгазьдә дә тапшырылырга тиеш.

Мөрәҗәгать итүче гаризаны һәм сканер аша чыгарылган документларны "Дәүләт контроле" ПТК" ФДМС аша көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган (танылканган) электрон документ рәвешендә тапшырган очракта, күрсәтелгән документларны кәгазьдә тапшыру таләп ителми.";

"Стандартка карата таләпләр эчтәлеге" графасының 2.6 пунктында түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

"Документларны алу ысуллары һәм мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы булган документларны тапшыру тәртибе шушы Регламентның 2.5 пунктында билгеләнде.

Мөрәҗәгать итүчедән югарыда санап үтелгән, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган документларны таләп итү тыела";

"Стандартка карата таләпләр эчтәлеге" графасының 2.9 пунктында түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

"Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

1. Мөрәҗәгать итүченең объекты федераль дәүләт экология күзәтчелегенә кертелүе;

2. Мөрәҗәгать итүченең материаллары составында ялган белешмәләр яисә төгәл булмаган мәгълүматлар булу, шул исәптән:

- Мөрәҗәгать итүченең материаллары составында фальсификацияле документлар булуы ачыклану;

- Хисаплылыкның ТР Табигать министрлыгының 30 номерлы боерыгында билгеләнгән таләпләргә җавап бирмәве.

Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк";

"Стандартка карата таләпләр эчтәлеге" графасының 2.13 пунктында түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә";

"Стандартка карата таләпләр эчтәлеге" графасының 2.14 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Дәүләт хезмәте һаваны кондиционерлау системасы, янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазланган биналарда һәм бүлмәләрдә күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга инвалидларның каршылыксыз үтеп керә алу мөмкинлеге тудырыла (бүлмәләргә уңайлы керү-чыгу һәм аның чикләрендә хәрәкәт итү).

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла";

"Стандартка карата таләпләр эчтәлеге" графасының 2.15 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Дәүләт хезмәте күрсәтүнең үтемлелек күрсәткечләре булып түбәндәгеләр санала:

документларны кабул итү, тапшыру эшләре башкарыла торган биналарның җәмәгать транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;

кирәкле санда белгечләр, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннар булуы;

дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакытлары турында мәгълүмат стендларында, "Интернет" челтәрендәге мәгълүмат ресурсларында, Министрлыкның рәсми сайтында тулы мәгълүмат булу;

электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәләрен гариза белән документларны электрон документлар рәвешендә Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша тапшырганда мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон рәвештә Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинетында алу мөмкинлеге (гариза белән документларны электрон документлар рәвешендә Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша тапшыру мөмкинлеген тормышка ашыргач);

инвалидларга бүтән затлар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачау итүче киртәләрне җиңүдә ярдәм күрсәтү.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документларны кабул итү һәм карау чорлары саклану;

дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу чоры саклану;

шушы Регламентны дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан бозуларга карата прецендентлар (нигезле шикаятьләр) булу (прецендентларның, шикаятьләрнең Министрлыкның һәм Министрлыктагы территориаль идарәләрнең дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затларының гомуми санына карата мөнәсәбәте);

мөрәҗәгать итүченең Министрлык белгечләре белән хезмәттәшлек итү саны:

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гариза белән документларны тапшырганда һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алганда, турыдан-туры – ике мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәтен алу өчен кирәкле гариза белән документларны почта аша җибәргәндә – юк (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинет аша җибәргәндә:

1. әгәр гариза белән документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланган (таныкланган) электрон документлар рәвешендә җибәрелсә, – турыдан-туры хезмәттәшлек итү таләп ителми;

2. әгәр гариза белән документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) электрон документлар рәвешендә җибәрелсә, – бер мәртәбәдән артык түгел.

Мөрәҗәгать итүче белән бер мәртәбә эшләү озынлыгы – 15 минуттан артык түгел.

Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза тапшыруны да кертеп, күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында гамәлгә ашырылмый.

Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан http://www.eco.tatarstan.ru сайтыннан, Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан алынырга мөмкин.";

2.16 пунктында:

"Стандартка карата таләпләр эчтәлеге" графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны һәм сканер аша чыгарылган электрон рәвештәге документларны "Дәүләт контроле" ПТК" ФДМС аша тапшыру мөмкинлеге бар.

Мөрәҗәгать итүче гаризаны һәм сканер аша чыгарылган документларны "Дәүләт контроле" ПТК" ФДМС аша көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) электрон документ рәвешендә тапшырган очракта, күрсәтелгән документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче (аның вәкиле) тарафыннан Министрлыкның тиешле территориаль идарәсенә кәгазьдә дә тапшырылырга тиеш.

Мөрәҗәгать итүче гаризаны һәм сканер аша чыгарылган документларны "Дәүләт контроле" ПТК" ФДМС аша көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган (таныкланган) электрон документ рәвешендә тапшырган очракта, дәүләт хезмәте алу өчен күрсәтелгән документларны кәгазьдә тапшыру, шулай ук мөрәҗәгать итүче (аның вәкиле) тарафыннан Министрлык территориаль идарәсеннән Хисаплылыкны Министрлыкның тиешле территориаль идарәсендә кәгазьдә кабул итү турында бәяләмә алу таләп ителми. Бу очракта Министрлыкның территориаль идарәсеннән Хисаплылыкны кабул итү турында бәяләмә электрон рәвештә мөрәҗәгать итүченең гаризада күрсәтелгән электрон адресына җибәрелә.";

"Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив акт" графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"210-ФЗ номерлы Федераль закон, 63-ФЗ номерлы Федераль закон";

3.1 пунктының 3.1.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3.3.1. Мөрәҗәгать итүче (аның вәкиле) кәгазьдә шәхсән, электрон рәвештә "Дәүләт контроле" ПТК" ФДМС аша, яисә почтадан заказлы хат итеп, кулга тапшыру турында тамгасы белән салынганнарның исемлеген күрсәтеп, гаризаны әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны (алга таба – документлар) кушып, әлеге Регламентның 1 таблицасында күрсәтелгән Министрлыкның тиешле территориаль идарәсенә тапшыра (җибәрә).

Мөрәҗәгать итүче гаризаны һәм сканер аша чыгарылган документларны "Дәүләт контроле" ПТК" ФДМС аша көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) электрон документ рәвешендә тапшырган очракта, күрсәтелгән документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче (аның вәкиле) тарафыннан Министрлыкның тиешле территориаль идарәсенә кәгазьдә дә тапшырылырга тиеш.

Мөрәҗәгать итүче гаризаны һәм сканер аша чыгарылган документларны "Дәүләт контроле" ПТК" ФДМС аша көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган (таныкланган) электрон документ рәвешендә тапшырган очракта, күрсәтелгән документларны кәгазьдә тапшыру таләп ителми.";

Гаризаны электрон формада җибәргән очракта сорала торган документларның сканер аша чыгарылган күчермәләре кушыла, гариза почтадан җибәрелгән, – мөрәҗәгать итүче тарафыннан таныкланган документлар.

Гариза тапшыру мөрәҗәгать итүчедән документлар рәсмиләштерү өлешендә ярдәм күрсәтүне таләп итми.

Дәүләт хезмәте күпфункцияле үзәк аша һәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннары аша күрсәтелми."

3.3 пунктының 3.3.14 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3.3.14. Министрлыкның территориаль идарә белгече:

Хисаплылыкны кабул итү яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында мәгълүматны Министрлыкның Бердәм бүленгән мәгълүмат-аналитика системасына (алга таба – ББМАС) кертә;

Хисаплылыкны кабул итү турында Министрлыкның территориаль идарәсе бәяләмәсенең икенче нөсхәсен яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хатның икенче нөсхәсен саклау өчен архивка юнәлтә;

мөрәҗәгать итүче гаризаны һәм сканер аша чыгарылган документларны "Дәүләт контроле" ПТК" ФДМС аша көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган (таныкланган) электрон документ рәвешендә тапшырган очракта, Хисаплылыкны кабул итү турында Министрлыкның территориаль идарәсе бәяләмәсен электрон рәвештә мөрәҗәгать итүченең гаризада күрсәтелгән электрон адресына җибәрә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: ББМАС кертелгән мәгълүмат, Министрлыкның территориаль идарәсе архивына юлланган Хисаплылыкны кабул итү турында Министрлыкның территориаль идарәсе бәяләмәсенең икенче нөсхәсе яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хатның икенче нөсхәсе, мөрәҗәгать итүченең гаризада күрсәтелгән электрон адресына җибәрелгән электрон рәвештә Хисаплылыкны кабул итү турында Министрлыкның территориаль идарәсе бәяләмәсе."

3.3 пунктының 3.3.15 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3.3.15. Министрлыкның территориаль идарәсе белгече мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) Хисаплылыкны кабул итү турында Министрлыкның территориаль идарәсе бәяләмәсенең беренче нөсхәсен тапшыра.

Мөрәҗәгать итүче гаризаны һәм сканер аша чыгарылган документларны "Дәүләт контроле" ПТК" ФДМС аша көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган (таныкланган) электрон документ рәвешендә тапшырган очракта, Хисаплылыкны кабул итү турында Министрлыкның территориаль идарәсе бәяләмәсе электрон рәвештә мөрәҗәгать итүченең гаризада күрсәтелгән электрон адресына җибәрелә. Бу очракта мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) Министрлыкның тиешле территориаль идарәсеннән кәгазьдә Хисаплылыкны кабул итү турында Министрлыкның территориаль идарәсе бәяләмәсен алу таләп ителми.

Мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) Хисаплылыкны кабул итү турында Министрлыкның территориаль идарәсе бәяләмәсен тапшыру мөрәҗәгать итүче килгән көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган Хисаплылыкны кабул итү турында Министрлыкның территориаль идарәсе бәяләмәсенең беренче нөсхәсе, мөрәҗәгать итүченең электрон адресына электрон рәвештә җибәрелгән Хисаплылыкны кабул итү турында Министрлыкның территориаль идарәсе бәяләмәсе";

4 бүлектә 4.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору түбәндәгеләрне үз эченә ала: мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылуны ачыклау һәм бетерү, шикаятьләр карау, тикшерүләр уздыру, мөрәҗәгать итүчеләрнең мөрәҗәгатьләре буенча карарлар кабул итү һәм җаваплар әзерләү, Министрлыкның вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмавына) карарлар әзерләү.

Административ процедуралар үтәлешен тикшереп тору рәвешләре түбәндәгеләргә карата тикшерүләр уздырудан гыйбарәт:

эшнең алып барылуына;

документларны карау нәтиҗәләренең законнардагы (шушы Регламенттагы) таләпләргә туры килүенә;

документларны кабул итүнең чорлары һәм тәртибе саклануга;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләр тапшыру чорлары һәм тәртибе саклануга.

Тикшерүләр планлы (Министрлыкның яртыеллык яисә еллык эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр уздырылганда дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле (комплекслы тикшерүләр) яки мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча мәсьәләләр каралырга мөмкин.

Әлеге Регламентның 3 бүлегендә билгеләнгән административ процедуралар башкарылуны тикшереп тору максатларында, дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә һәм карарлар кабул ителгәндә министрга дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмә бирелә";

5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче Министрлыкның, шулай ук аның дәүләт хезмәтен күрсәтүче вазыйфаи затының яисә дәүләт граждан хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) мөрәҗәгать итүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү

5.1. Дәүләт хезмәте алучылар Министрлыкның һәм/яисә Министрлыкның территориаль идарәсенең, Министрлыкның һәм/яисә Министрлыкның территориаль идарәсе вазыйфаи затының, яисә Министрлыктагы дәүләт хезмәткәренең һәм/яисә Министрлыкның территориаль идарәсе дәүләт хезмәткәренең карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр шикаять белдерү хокукына ия, – Министрлыкка. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә министр тарафыннан кабул ителгән карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауга) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына белдерелә.

Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны теркәү вакыты бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган документлар таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) Министрлыкның, Министрлыкның һәм/яисә Министрлыкның территориаль идарәсе вазыйфаи затының дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда җибәрелгән басма хаталарын яки хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта.

5.2. Дәүләт хезмәтен алучылар тарафыннан шикаять почта аша, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Интернет-кабул итү, Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы, күпфункцияле үзәк аша җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә кабул итеп алынырга мөмкин.

5.3. Дәүләт хезмәте алучыларның шикаятендә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) шикаять ителә торган Министрлыкның, Министрлыкның һәм/яисә Министрлыкның территориаль идарәсе вазыйфаи затының яисә дәүләт граждан хезмәткәренең исеме;

мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның урнашкан урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

Министрлыкның, Министрлыкның һәм/яисә Министрлыкның территориаль идарәсе вазыйфаи затының яисә дәүләт граждан хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

мөрәҗәгать итүче Министрлыкның, Министрлыкның һәм/яисә Министрлыкның территориаль идарәсе вазыйфаи затының яисә дәүләт граждан хезмәткәренең карары һәм гамәле (гамәл кылмавы) белән ризалашмавына нигез булган дәлилләр.

5.4. Министрлыкка һәм/яисә Министрлыкның территориаль идарәсе килгән шикаять шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат тарафыннан аны теркәгәннән соң 15 эш көне дәвамында, ә Министрлыкның һәм/яисә Министрлыкның территориаль идарәсе вазыйфаи затының дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда җибәрелгән басма хаталарын яки хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәгәннән соң биш эш көне дәвамында карап тикшерелергә тиеш.

Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслый торган документларның күчермәләре теркәлергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа теркәлә торган документларның исемлеге китерелә.

5.5. Шикаять мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән яки аның вәкаләтле заты тарафыннан имзалана.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча Министрлык һәм/яисә Министрлыкның территориаль идарәсе түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, Министрлыкның территориаль органы тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә документларда җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә аларны алу Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук бүтән рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

Шушы пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соң бер көн узганчы мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә аның ихтыяры буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.7. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга

вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.";

2 нче кушымтада "М.У." сүзләрен "М.У. (булган очракта)" сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле Кушымта (белешмә) өстәргә:

"Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының калдыклар барлыкка килү, аларны файдалану, йогышсызландыру һәм урнаштыру турында хисаплылык (статистика хисаплылыгыннан кала) турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кушымта (белешмә)

**Калдыклар барлыкка килү, аларны файдалану, йогышсызландыру һәм урнаштыру турында хисаплылык (статистика хисаплылыгыннан кала) турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган вазыйфаи затларның реквизитлары**

**Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы**

| Вазыйфасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Министр – Габделганиев Фәрит Солтан улы | (843)267-68-01<br>(843)267-68-02 | Farid.Abdulganiev@tatar.ru |
| Министрның әйләнә-тирәлекне саклау буенча беренче урынбасары – Камалов Рөстәм Илдар улы | (843)267-68-19 | Rustem.Kamalov1@tatar.ru |
| Дәүләт экология экспертизасы һәм әйләнә-тирәлеккә йогынтыны нормага салу идарәсе башлыгы – Шәһидуллина Рәисә Габдулла кызы | (843)267-68-90 | Raisa.Shagidullina@tatar.ru |
| Әйләнә-тирәлеккә йогынтыны нормага салу бүлеге башлыгы – Богатырев Сергей Адольфович | (843)267-68-81<br>(843)267-68-49<br>(843)264-49-37 | Sergey.Bogatyrjov@tatar.ru |
| Эш башкару бүлеге | (843)267-68-04<br>(843)267-68-05 | eco@tatar.ru. |
| Үзәк территориаль идарәсе башлыгы – Королев Петр Сергеевич | (843)267-68-32 | Petr.Korolev@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| Төньяк территориаль идарәсе башлыгы – Шаһиәхмәтов Радик Дамир улы | (84366)3-21-61 | sevtu@mail.ru |
| Идел аръягы территориаль идарәсе башлыгы – Васин Николай Алексеевич | (84374)3-11-02 | zvtu@bk.ru |
| Идел-Чулман территориаль идарәсе башлыгы – Әхмәтҗанов Рафис Габделхак улы | (84342)5-35-19 | Rafis.Ahmetzyanov@tatar.ru |
| Чулман аръягы территориаль идарәсе башлыгы – Лобанов Алексей Геннадьевич | (8555)45-66-56 | Aleksey.Lobanov@tatar.ru |
| Чулман буе территориаль идарәсе башлыгы – Гарипов Наил Габбас улы | (8552)59-36-39 | Nail.Garipov@tatar.ru |
| Ык буе территориаль идарәсе башлыгы – Мөстәкыймов Хәлил Салих улы | (85592)7-73-86 | Halil.Mustakimov@tatar.ru |
| Көньяк-Көнчыгыш территориаль идарәсе башлыгы – Маликов Альберт Әүхәт улы | (8553)33-03-25 | Albert.Malikov@tatar.ru |

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты**

| Вазыйфасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының җир асты байлыкларыннан, табигый ресурслардан файдалану һәм әйләнә-тирәлекне саклау мәсьәләләре бүлеге башлыгы – Фәсхетдинов Марат Гайса улы | (843)264-77-78 | Marat.Fashutdinov@tatar.ru |

2. Хокукый тәэминат бүлегенә (М.Р. Галиәкбәров) шушы боерыкның дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча министрның беренче урынбасары Р.И. Камаловны җаваплы итеп билгеләргә.

Министр Ф.С. Габделганиев